
# Яңа велосипед

Кечкенә велосипедта
Мин йөри идем элек.
Зурысын алган әтием:
«Дәү үстең инде», — диеп.

Дусларга бик ошады ул,
Әй мактыйлар: «Шәп бигрәк!
Безне дә йөртерсең, яме?»
«Юк! — дидем. —
Ул бит бүләк!»

Өстенә менеп утыргач
Егылып төштем: «Ай-ай!»
Әйтте кебек велосипед:
«Син саран булма алай!»





# Курчагым

Курчак бүләк итте әти
Туган көнемдә миңа.
Шундый сөйкемле, матур ул,
Сөенеп йөрим шуңа.

Аның белән бергәләшеп
Уйнап туймыйм көнозын.
Ашатам да, йоклатам да –
Әйтерсең нәни кызым.



Еласа юатам аны,
Иркәлим курчагымны.
Әни булу җиңел түгел —
Аңладым менә шуны.

## Әбием һәм песием

Безнең песи, ни булса да,
Эндәшә «мияу» диеп,
Аның нәрсә сораганын
Әбием тора белеп.

Кирәк икән, Мырауҗанны
Тәмле сөт белән сыйлый.
Бер карасаң, назлап кына,
Йомшак йонынннан сыйпый.

Рәхмәтен әйтә песи дә:
Тычканнар тота өйдә.
Кайчакларда концерт куя
«Мыр да мыр-р» дигән көйгә.

Аңлашып кына торгач бит,
Һәр эштә бар бәрәкәт.
Әбигә дә, песигә дә
Дус булып яшәү рәхәт!



# Кире йокы



Килеп җиткәч уенның
Иң-иң кызык турына,
Әти-әни икәүләп
Йоклатырга тотына:
— Тышта шундый караңгы,
Тәрәзәгә бак инде.
Уйный-уйный арыдың,
Кич җиткән бит, ят инде!
Ә иртән иртүк килеп,
Сәгатькә карый-карый,
Әти-әни, җыйнаулап,
Мине уята башлый:
— Күрче, урамда якты,
Кояштан оял инде.
Бакчага барасың бар,
Бәбкәем, уян инде!
Ятасы килми кичтән,
Торасы килми иртән.
Эх, бу йокы! Әйтегез,
Ник шундый кире икән?!